**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР №12**

Иске Каразирек ав. 20 май 2025 ел

“Җир салымы турында”гы
kararга үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеген КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советының 2024 елның 29 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы 29 санлы карарына (алга таба-Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 3 пунктындагы бер абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләре өчен салым түләүдән салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләрен азат итәргә:»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә., «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы И.Р.Гәрәев